# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Муса Җәлил**

Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елда Ырынбур өлкәсе Мостафа авылында туа. Ул кече яшьтән үк зирәк һәм хыялга бай бала була. Күп укый, һәр нәрсәне белергә тырыша. Оста итеп мандолинада уйнарга өйрәнә. Рәсем ясарга ярата. Муса Ырынбурда «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый.

Муса 10-11 яшьләрендә шигырьләр дә язып карый. Ләкин алар югала. Матбугатта иң беренче булып унөч яшендә язылган «Бәхет» шигыре (1919) басыла. 1922 елда ул Казанга килә һәм 1923-1925 елларда Казан педагогия институтының рабфагында укый. Ул 1931 елда Мәскәү университетының әдәбият бүлеген тәмамлый. 1933 елның җәендә Дергачи районында татарча газета оештыра. 1939 елда Җәлилне Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Сугышка кадәрге елларда шагыйрь бик күп шигырьләр, җырлар, «Хат ташучы» поэмасын, «Алтынчәч», «Илдар» исемле опера либреттоларын яза.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул үзен фронтка җибәрүләрен сорый. Ләкин 1942 елның җәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. 1944 елның 25 августында фашистлар М. Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен җәзалыйлар. (157 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Мостай Кәрим**

Мостай Кәрим 1919 елның 20 октябрендә Башкортстанның хәзерге Чишмә районының Келәш исемле татар авылында крестьян гаиләсендә туа. Милләте буенча татар, әмма соңрак милләтен «алыштыра».

1941 елда Башкорт дәүләт университетының тел һәм әдәбият факультетын тәмамлый. Бөек Ватан сугышы башлану белән фронтка китә, сугышта мина ярчыгы күкрәгенә тиеп, чак кына йөрәгенә барып җитми. Госпитальдә ятып дәваланып чыккач, Воронеж фронтына башкорт телендә чыгарга тиешле газетада эшләргә дип җибәрелә. Шул ук фронтның «За честь Родины» (Ватан намусы өчен) рус газетасында һәм «Ватан намусы өчен» татар газетасында эшли башлый. Алдынгы эшелон гаскәрләренә бара, мәкаләләр, очерклар һәм новеллалар яза.

1930 елларда ук яза башлый. Беренче шигырьләре татар телендә Чишмә районының "Сталинчы" гәзитендә басыла. 1938 елда «Отряд кузгалды» дигән беренче шигырь җыентыгы нәшер ителә. Барысы 100дән артык шигърият һәм проза китаплары, 10нан артык пьесалары дөнья күрә. Мостай Кәримнең әсәрләре берничә дистә телгә тәрҗемә ителгән.

2005 елның 21 сентябрендә Уфада вафат була. Уфаның мөселман зиратында җирләнгән. (146 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Фатих Кәрим**

Фатих Кәрим 1909 елның 9 гыйнварында Россия империясенең элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе Ает авылында мулла гаиләсендә туа. Үз авылында мәдрәсәдә укый.

Шагыйрь 12 яшенә кадәр туган авылында яши, укый. 1922 елда Ф.Кәрим Бәләбәй педагогия техникумының әзерлек курсына укырга керә. 1924 елда ул Казанга килү белән, шигырь язу белән мавыга башлый. 1926-1927 елларда аның «Төнге урам баласы», «Урман» исемле шигырьләре басыла.

Ф.Кәрим 1925 елның көзенә кадәр Н.К. Крупская исемендәге балалар йортында тәрбияләнә. 1929 елда Казанда Җир төзү эшләре техникумын тәмамлый. Шушы елларда аның беренче шигырьләре матбугатта басылып чыга. 1931 –1933 елларда Кызыл Армия сафларында хезмәт итеп кайта. 1938 елда Ф.Кәрим кулга алына.

Югары суд утырышы шагыйрьне 10 елга төрмәгә ябылуга хөкем итә. Аны Коми якларындагы төрмәгә җибәрәләр. Төрмәдә утырганда да, ул иҗат итүдән туктамый.

1942 елның февраленнән 1945 елның февраленә кадәр, өч ел буена, Фатих Кәрим фронтның алгы сызыгында була. Сугыш бетәргә санаулы көннәр калганда, 1945 елның 19 февралендә, 36 яшьлек шагыйрь дошман пулясыннан һәлак була. (154 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Әмирхан Еники**

Әмирхан Еники 1909 елның 17 февралендә элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылында туган.

Яшьтән үк әдәбият, иҗат эше белән кызыксынган Әмирхан Еники 1925 елның җәендә Казанга килә һәм китап кибетенә курьер булып эшкә урнаша. Бер елдан ул Казан университеты каршындагы рабфакка укырга керә. Шушы чорда көндәлек матбугат битләрендә аның әдәби парчалары һәм хикәяләре күренә башлый.

1927—1933 еллар арасында Ә. Еники Донбасста — ликбез курсларында укытучы, Казан мех фабрикасында — сортировщик, «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә штаттан тыш хәбәрче хезмәтендә була. 1931—1933 елларда Казанда Хезмәтне фәнни оештыру институтында (ИНОТ) укый. 1941—1945 елларда әдип — Ватан сугышы фронтында: хәрәкәттәге армиянең хуҗалык һәм каравыл частьләрендә рядовой солдат булып хезмәт итә.

Армиядән кайткач, Ә. Еники берникадәр вакыт «Совет әдәбияты» журналында әдәби хезмәткәр, аннары Татарстан радио комитетында әдәби тапшырулар бүлеге редакторы булып эшли. 1950—1952 елларда Казан авиация техникумында татар теле укыта, 1953 елда ул бөтенләе белән профессиональ язучылык хезмәтенә күчә. 1946 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 2000 елның 16 февралендә Казанда вафат була. (158 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Абдулла Алиш**

Абдулла Алиш 1908 елның сентябрендә Көек авылында туган. Китап дөньясына ул бик кечкенәдән тартыла. Абдулла Ямбакты мәдрәсәсендә генә укып калмый, 1923—1927 елларда Спас шәһәрендәге рус мәктәбендә белем ала, аның беренче шигырьләре шунда языла.

1927 елдан Казанга килеп, җир төзелеше техникумын тәмамласа да, Абдулла әдәбиятка, язу эшенә тартыла, балалар журналында («Ялкын») аның әкиятләре дөньяга чыга. А. Алиш әкият остасы булып танылып китә (егерме бишләп әкиятнең авторы ул): «Сертотмас үрдәк», «Нечкәбил», «Куян кызы», «Койрыклар», «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык» һәм тагын башка күп кенә әкиятләр иҗат итә.

1941 елда, фашистик Алмания белән сугыш башлангач, А. Алиш фронтка китә. Каты сугышларда чолганышта калып, әсир төшә. Ул Муса Җәлил җитәкләгән яшерен оешмага керә һәм фашистларга каршы көрәш башлап җибәрә. Әмма бу дәһшәтле көрәш — зур батырлык, гомереңне сораучы соңгы көрәш.

А. Алиш туган иленә әйләнеп кайта алмаган. 1944 елның августында Совет хәрби әсирләренең яшерен оешмасы эшендә катнашканы өчен Плетцензее төрмәсендә немец фашистлары тарафыннан җәзалап үтерелә. (151 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Әхмәт Ерикәй**

Әхмәт Ерикәй Өлкеде дигән авылда ярлы крестьян гаиләсендә туа. Гаилә ишле булу сәбәпле, Әхмәт кечкенәдән үк җәйләрен көтү көтә, авыл байларына көнлекче булып тора, кышларын мәдрәсәдә белем ала. Үсә төшкәч, этисе белән Златоуст, Түбән Уфалы шәһәрләрендә төрле эшләрдә эшли. Бер үк вакытта белемен күтәрә, шигърият белән кызыксына, рус телен һәм әдәбиятын үзләштерә. 1920 елда комсомол, 1924 елда партия сафларына алына. 1927 елга кадәр ул кантон участок судында һәм партия комитетында эшли. Шул елларда беренче шигырьләре матбугатта басыла башлый.

1927 елдан Ә. Ерикәй Мәскәү Дәүләт журналистика институтында укый башлый, Мәскәүдәге татарча газета-журналларда әсәрләрен бастыра, үзе дә редакцияләрдә эшли.

Бөек Ватан сугышы елларында Ә. Ерикәй фронт газеталарында хезмәт итә, 1945-1950 елларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе булып эшли. Ул 1946 һәм 1950 елларда СССР Верховный Советы депутаты итеп сайлана. Шагыйрь 1967 елның 15 сентябрендә Мәскәүдә вафат булды.

Татар совет әдәбиятында Ә. Ерикәй беренче чиратта җырлар язучы шагыйрь булып танылды. Аның сүзләренә язылган җырлар халык арасында киң таралган. (155 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Гаделша Кутуев**

Гаделша Кутуев 1903 елның 28 ноябрендә Сарытау губернасының Кузнецк өязе Татар Кынадысы авылында мул тормышлы крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылындагы мәктәптә ала. Гаделша Самара губернасы Алексеевка дигән авылда урыс мәктәбендә укуын дәвам итә. 1920 елда унҗиде яшьлек Гадел Казанга килә һәм политехника институтының химия факультетына керә. Казан Татар-башкорт хәрби мәктәбенә әдәбият укытучысы булып эшкә керә.

1925 елда Гадел Кутуй Казан шәрекъ педагогия институтының урыс теле һәм әдәбияты бүлегенә керә.

1942 елның июнендә Г.Кутуй фронтка китә һәм башта Сталинградны саклаучы Дон фронтының авыр гвардия миномет бригадасы сәяси бүлегендә хезмәт итә, Идел буенда Сталинград сугышында катнашканы өчен, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

Сталинградтан соң Кутуй гвардия бригадасы составында Волхов, Курск, Брянск, Бөек Лукалар һ.б. шәһәрләрне азат итүдә катнаша. 1944 елның көзендә ул Беренче Белоруссия фронтындагы татар телле «Кызыл Армия» газетасы редакциясенә күчерелә. 1944 елда исә ул Казанга, иҗади ялга кайта һәм «Рөстәм мажаралары» дигән мажаралы-фантастик повестен яза. 1945 елның 15 июнендә Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев вафат була. (157 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов**

Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов 1911 елның 28 декабрендә элекке Пенза губернасының Краснослободск өязе Иске Аллагол авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Н.Нариманов исемендәге 27 нче номерлы татар урта мәктәбендә укыганда әдәби иҗат эше белән кызыксына башлый, беренче шигырьләрен яза. Иҗат тәҗрибәләреннән берсе – «Әнвәр тегермәне» исемле шигыре – «Октябрь баласы» журналында басылып та чыга. 1940 елда исә читтән торып М.Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый.

1941 елның августында Г.Әпсәләмов сугышка китә. Әүвәл Карелия фронтының диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры, аннары 1943 елның җәеннән 1945 елның маена кадәр шул ук фронтта чыккан «Ватан өчен сугышка» дигән татарча газетаның җаваплы сәркәтибе булып эшли.

Г.Әпсәләмовның әдәби тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаеклы. Ул рус язучылары А.Гайдарның «Тимур и его команда», Э.Казакевичның «Весна на Одере», А.Фадеевның «Молодая гвардия» романнарын тәрҗемә итә.

Фронттагы һәм татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен ул Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә. Габдрахман Әпсәләмов 1979 елның 7 февралендә Казанда вафат була. (153 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Сибгат Хәким**

Сибгат Хәким 1911 елның 4 декабрендә Татарстанның Әтнә районы Күлле-Киме авылында крестьян гаиләсендә туа. 1931 елда Казанга килеп Татрабфакка укырга керә, ә икенче курстан Казан дәүләт педагогия институтына күчә. 1937 елда ул Татарстан китап нәшриятында, аннары «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә эшли.

Ватан сугышы башлангач, 1941 елның июнь аенда армиягә алынып, Сибгат Хәким 1946 елның маена кадәр хәрби хезмәттә була. Армиядән кайткач, ул кабат "Совет әдәбияты" журналы редакциясенә эшкә урнаша, ә 1950 елдан язучылык эше белән генә шөгыльләнә. Аның беренче шигырьләре утызынчы еллар башында «Атака», «Совет әдәбияты» журналлары һәм «Кызыл яшьләр» газетасы битләрендә дөнья күрә.

Сугыш темасы аның бөтен иҗаты буенча кызыл җеп булып сузыла. Бу олы тема эпик колачлыгы һәм фәлсәфи тирәнлеге белән «Курск Дугасы», «Дала җыры», «Бакчачылар», «Дуга» һәм «Күги» кебек поэмаларында аеруча калку гәүдәләнә.

С. Хәким — дистәләгән җырлар авторы. «Юксыну», «Фазыл чишмәсе», «Таң атканда», «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Башка берни дә кирәкми», «Кайда да йөрәктә» кебек җырлар халык арасында зур популярлык казаналар. (154 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Гомәр Бәширов**

Гомәр Бәширов 1901 елның 7 гыйнварында элеккеге Арча вулысының Яңа Сала авылында туа. 7 яшеннән мәзиндә кыш буе белем ала, икенче елны мәдрәсәгә керә. 1919 елның җәендә язучы Арча өязенең Урта Бирәзә авылында укытучы булып эшли башлый. 1920 елда яшь укытучы Кызыл Армиягә алына. Армиядә өч ел хезмәт итә.

Армиядән кайткач, совет милициясе һәм юстиция органнарында эшли. 1932 елдан ул "Кызыл Татарстан" гәзитендә, бераздан "Совет әдәбияты" журналында эшли башлый. Аның бик күп мәкаләләре, очерклары, хикәяләре басыла. 1937 елда язучының атаклы "Сиваш" повесте басылып чыга. Бу әсәр бик тиз тарала һәм Г. Бәшировны күренекле язучылар сафына чыгара.

1968 елда язучы татар халкының гореф-гадәтләрен яктырткан "Туган ягым – яшел бишек" исемле автобиографик әсәрен тәмамлый. 1978 елда Г. Бәшировның "Җидегән чишмә" романы басылып чыга.

Г. Бәширов – фольклор әсәрләрен туплап, бастырып чыгару эшенә дә күп көч куйган галим. "Туксан тугыз мәзәк", "Мең дә бер мәзәк" исемле китаплар – аның хезмәт нәтиҗәсе.

Гомәр Бәширов 1999 елның 7 маенда Казанда вафат була. (152 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Торатау.**

Торатау тавы – уникаль табигый һәйкәл һәм Башкортстанның төп символларының берсе. Тау Ишембай шәһәре һәм Ишембай районы гербында сурәтләнгән. Торатауны еш кына шихан дип кенә атыйлар. Гомумән, шихан-сөзәк битле ялгыз тауның географик атамасы. Ишембай тирәсендә барлыгы өч Шихан — Куштау, Юрактау һәм Торатау. Кайчандыр Шахтау да булган. Торатау-җир йөзендәге иң борынгы тауларның берсе, аның яше якынча 285 миллион ел.

Торатау битендә Башкортстан Республикасының, Россиянең Кызыл китабына кертелгән бик күп сирәк үсемлекләр төре үсә. Монда шулай ук башка бер җирдә дә үсми торган һәм бик аз урыннарда сакланып калган борынгы флора да бар.

Тау итәгендәге Тугар-Салган күле, башкорт теленнән тәрҗемә иткәндә-елан күле. Күл шулай ук табигать һәйкәле, Башкортстанда иң тирән карст күлләренең берсе булып тора. Борынгы халыклар өчен Күл, Торатау кебек үк, изге булган.

Калкулык итәгеннән агып торган елга да, тыныч кына җәелеп яткан күл дә үз суларында әйләнә-тирә дөньяның бөтен гүзәллеген чагылдыра. Төрле якка гаҗәеп күренеш җәелә. Әйтеп бетергесез матурлык! (148 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Куштау.**

Башкортстанда, Стәрлетамак шәһәреннән ерак түгел, гаҗәеп таулар-шиханнар бар. Болар борынгы тау тезмәсеннән сакланган аерым торучы калкулыклар. Шул шиханнарның берсе Куштау атамасын йөртә. Башкортчадан тәрҗемә иткәндә Куштау- кош-тау дигәнне аңлата. Икенче версия буенча, Куштау-парлы тау дигәнне аңлата. Куштау биек түгел, ләкин бик матур тау. Шиханның биеклеге – 251 метр чамасы. Куштау-мәйданы буенча иң зур шихан. Көньяктан һәм көнбатыштан тауны катнаш урман белән капланган матур ярлары булган Агыйдел елгасы урап уза. Калкулык итәгеннән агып торган елга үз суларында әйләнә-тирә дөньяның бөтен гүзәллеген чагылдыра.

Куштауның хайваннар дөньясы да, үсемлекләр дөньясы да бик бай. Галимнәрнең соңгы мәгълүматларына караганда, тау территориясендә инде 40 тан артык хайван һәм үсемлек төрләре табылган, алар Башкортостан Республикасының, Россиянең Кызыл китапларына кертелгән.

Куштау чаңгы шуарга яратучылар өчен иң кызыклы урын. Бирегә яңа гына чаңгыга басканнар да, тәҗрибәле тау чаңгычылары да килә. Куштау тавында еш кына спорт ярышлары уздыралар.Чаңгычылар Куштауның текә тау итәгеннән рәхәтләнеп шуалар. Туристлар фикеренчә, биредәге чиста һава Швейцарияне хәтерләтә. Куштауның көнчыгыш битендә шул ук исемдәге тау чаңгысы комплексы да урнашкан. (160 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Йөрүзән елгасы.**

Йөрүзән – Чиләбе өлкәсе һәм Башкортстан территориясе буенча агучы елга. Караидел елгасының сул кушылдыгы. Елга Зур Ямантау битләрендә, Көньяк Урал тауларының үзәгендә башланып, матур таулар һәм кыялар арасында ага. Ул башта Башкортстан, аннары Чиләбе өлкәсе буйлап һәм калган юлын яңадан Башкортстан буйлап дәвам итә. Озынлыгы 404 километр тәшкил итә. Башкортстан территориясендә озынлыгы 224 километр тирәсе. Кыяларга, мәгарәләргә, чиста минераль чишмәләргә бай, Уралның иң матур елгаларының берсе, республиканың иң эре ун елгасы исемлегенә керә. Йөрүзән елгасының барлыгы 36 кушылдыгы бар.

Йөрүзән урманнар белән капланган тауларның ак кыялары арасыннан бормалы юл салып, бик тиз ага. Бу елга балыкка бай. Биредә Уралның тау һәм тигезлек елгаларына хас барлык балыклар да бар: чуртан, алабуга, чабак, голавль, күпкән, хариуслар.

Матур яңгырашлы "Йөрүзән" атамасы башкорт теленнән "зур үзән" яки "җирдә үзән барлыкка китергән елга" дип тәрҗемә ителә. Башка тәрҗемәләр дә бар: "тиз, шаян елга"," эре елга","җырлы елга". Гүзәл Йөрүзән турында бик күп шигырьләр һәм җырлар язылган. Елганың матурлыгын үзенең әсәрләрендә якташыбыз Рәми Гарипов данлаган. (158 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Ямантау.**

Башкортстанның Белорет шәһәреннән төньякта серле табышмаклар белән уралган Ямантау тавы урнашкан. Бу Көньяк Уралның иң биек тавы булып санала. Аның биеклеге 1640 метрга җитә. Атамасының килеп чыгышы "Яман" начар тау дип тәрҗемә ителә. Тау туристлар өчен тулысынча ябык, шуңа күрә еллар узган саен дөреслеккә тәңгәл килмәгән бик күп табышмаклар һәм риваятьләр белән уратылган.

Мондый атама барлыкка килүнең сәбәбе таш бормалы тау битләрендә яшәп, кешеләргә күп мәшәкатьләр китергән аюлар булырга мөмкин. Тагын да куркынычрак һәм серлерәк версия булып, күп гасырлар элек тау башында менәргә батырчылык иткән кыюларны һәлак иткән явыз рухлар яшәгәнлеге турында сөйли. Җирле халык тау янында кешеләрнең югалуының реаль очракларын да белә.

Шулай ук тау үзенең сәгатьләр буе адашып йөрерлек куе томаннары, кырыс һава шартлары, тайга һәм сазлыклары белән данлыклы. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, тау башында кар августка кадәр эреми. Мөгаен, шуның белән бергә барлык факторлар да тауны җирле халык күзендә «усал» иткәндер.

Тау Башкортстанда ябык территориядә урнашкан, шуңа күрә аңа менү мөмкин түгел. (156 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Уфа шәһәре.**

Уфа шәһәре Башкортстан республикасының башкаласы. Караидел белән Дим елгаларның Агыйдел елгасына кушыла торган урынында урнашкан. Халкыбыз тарихында Уфа аерым урын алып тора: ул милли, мәдәни, дини һәм иҗтимагый тормышның иң эре үзәкләренең берсе булып тора. Уфа безнең илдәге зур шәһәрләр исәбенә керә. “Агыйдел аккошының” канатлары 65 километрга җәелә. Уфа киңлекләрендә яңадан-яңа матур бистәләр барлыкка килә. Яшьләр, Урал, Сипайлы, Дим исемле яңа бистәләрдә күпме кеше яши!

XVI гасырда нигез салынган күпмилләтле шәһәр сәүдәгәрләр рус һәм шәрык архитектурасы сыйфатларын үзенә сеңдергән. Биек елга яры өстендә илнең иң биек атлы сыны – башкорт халкы герое Салават Юлаев һәйкәле тора.

Башкалабыз елдан – ел үзгәрә, матурлана. Агыйделнең биек ярында ул дүрт гасырдан артык мәһабәт басып тора. Каланың  халкы горурланырлык бай тарихы бар. Безнең өчен аның үткәне дә, бүгенгесе дә, киләчәге дә кадерле, якын һәм изге.

Шәһәрләр дә балалар сымак. Үскәннәре сизелми дә кала! Ике елга кушылган җирдә, саф дулкыннар арасында гүзәл аккошмбулып йөзгән Уфа шулай үсә, купшылана. Ул үзенең тагын да яктырак, бөек киләчәгенә омтыла. (159 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**